**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О комплексной системе мониторинга межнациональных и межконфессиональных отношений и раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве в Республике Татарстан»

В целях совершенствования комплексной системы мониторинга межнациональных и межконфессиональных отношений и раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве в Республике Татарстан **постановляю**:

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 25 апреля 2015 года № УП-414 «О комплексной системе мониторинга межнациональных и межконфессиональных отношений и раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве в Республике Татарстан» следующие изменения:

а) пункт 5 после слов «Управлению Федеральной миграционной службы по Республике Татарстан,» дополнить словами «Управлению Министерства юстиции Российской Федерации по Республике Татарстан,»;

б) пункт 8 Положения о комплексной системе мониторинга межнациональных и межконфессиональных отношений и раннего предупреждения конфликтов на религиозной и национальной почве в Республике Татарстан изложить в следующей редакции:

«8. Участниками комплексной системы мониторинга являются:

Кабинет Министров Республики Татарстан;

Департамент Президента Республики Татарстан по вопросам внутренней политики;

Управление Президента Республики Татарстан по работе с обращениями граждан;

Министерство культуры Республики Татарстан;

Управление записи актов гражданского состояния Кабинета Министров Республики Татарстан;

прокуратура Республики Татарстан (по согласованию);

Министерство внутренних дел по Республике Татарстан (по согласованию);

Управление Федеральной миграционной службы по Республике Татарстан (по согласованию);

Управление Министерства юстиции Российской Федерации по Республике Татарстан (по согласованию);

Территориальный орган Федеральной службы государственной статистики по Республике Татарстан (по согласованию);

Республиканское агентство по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа»;

Министерство информатизации и связи Республики Татарстан;

Министерство образования и науки Республики Татарстан;

Министерство труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан;

Министерство по делам гражданской обороны и чрезвычайным ситуациям Республики Татарстан;

Министерство экономики Республики Татарстан;

Министерство по делам молодежи и спорту Республики Татарстан;

органы местного самоуправления в Республике Татарстан (по согласованию);

Академия наук Республики Татарстан;

институты гражданского общества: общественные объединения, общественные и религиозные организации, представители экспертного сообщества, средства массовой информации (по согласованию).».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань,Кремль
14 ноября 2015 года
№ УП-1095

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне комплекслы мониторинглау системасын камилләштерү һәм дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы турында» 2015 елның 25 апрелендәге ПУ-414 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 5 пунктта «Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә,» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе,» сүзләрен өстәргә;

б) Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли җирлектәге низагларны алдан кисәтүне комплекслы мониторинглау системасы турында нигезләмәнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Комплекслы мониторинглау системасында катнашучылар түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты;

Татарстан Республикасы Президентының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе;

Татарстан Республикасы прокуратурасы (килешү буенча);

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча);

Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча);

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча);

Дәүләт статистикасы буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы;

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

Татарстан Республикасы Граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;

Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе;

граждан җәмгыяте институтлары: җәмәгать берләшмәләре, иҗтимагый һәм дини оешмалар, экспертлар берләшмәләре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре (килешү буенча).».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 14 ноябрь
№ ПУ-1095